РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Глава**
**Уразлинского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Уразлы**
**авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Мира, 7,с. Уразлино, 422838
тел. (8277)33-2-31, факс: (8277) 33-2-31
ОКПО 94304522, ОГРН 1061672020497
ИНН/КПП 1622004732/162201001

Тынычлык урамы, 7,Уразлы авылы, 422838,
тел. (8277)33-2-31, факс: (8277) 33-2-31
ОКПО 94304522, ОГРН 1061672020497
ИНН/КПП 1622004732/162201001

# КАРАР

**14 апрель 2021ел** **№ 4**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлегенең Кече Карамалы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 26 апрелендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлегенең Кече Карамалы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлегенең Кече Карамалы авылында 2020 елның 4 декабрендә кабул ителгән 3 нче номерлы халык җыены нәтиҗәләре турында карарга үзгәрешләр кертү белән килешәсезме?

- 7 абзацта «МТЗ-82 өчен КУН-10 сатып алу» сүзләрен « МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар сатып алу» сүзләренә алмаштырырга”.

"ӘЙЕ" “ЮК”

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга) :

- ТР, Кама Тамагы районы, Уразлы авылы, Тынычлык урамы, 7;

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Карамалы авылы, Кече урамы, 1;

- ТР, Кама Тамагы районы, Салтыган авылы, Урта урамы, 1,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Уразлы авыл җирлеге**
**башлыгы** **М.Г.Хәмидуллин**